ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
КАРАРЫ

2019 ЕЛНЫҢ 27 НОЯБРЕ №33

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
“Шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе” муниципаль берәмлеге
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябреннән “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартыннан “Җирле референдум турында”гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Шәһәр тибындагы Уруссу бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставы һәм 2019 елның 24 ноябрендә узган җирле референдумда кабул ителгән 75 санлы карарны гамәлгә ашыру максатында, ТР Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе башкарма комитеты карары:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе гражданнарының үзара салым акчасы җыю тәртибен раслау.

2. Әлеге карарны “Ютазы таңы”-“Ютазинская новь” район газетасында бастырырга, ТР Ютазы муниципаль районының jutaza.tatar.ru рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru. интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Житәкче вазифаларын башкаручы Р.Ә.Шәрипов

Шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары
карарына
1 нче кушымта
2019 елның__________ №_____

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсендә гражданнардан
үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 2020 елның 28 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар белдергән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, башкарыла.

3. Үзара салым түләүләреннән түбәндәге категория гражданнар азат ителә:
а) Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгән затлар;
б) 1,2 төркем инвалидлар, балачактан инвалид кешеләр.

4. Аерым категория гражданнар өчен:
а) көндезге бүлектә укучы студентлар өчен түләү 200 сум тәшкил итә, ягъни җирле референдум карары белән билгеләнгән сумманың 50 проценты.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында, “Ютазы таңы”- “Ютазинская новь” район газетасында бастырып чыгару юлы белән гражданнарга, яисә мәгълүмат стендларында халыкка хәбәр итеп яисә почта элемтәсе аша таратыла.
Хәбәрнамәдә гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы буенча федераль казна идарәсенең шәхси счетына (Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы) керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлардан исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия оешмалар һәм почта аша күчерергә (исәп-хисап оешмалары), Урыссу бистәсе башкарма комитеты кассасы аша яисә https://uslugi.tatarstan.ru/и Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша башкарыла.

8. Касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

9. Билгеләнгән вакытка түләнмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары
карарына
1 нче кушымта
2019 елның__________ №_____

ХӘБӘРНАМӘ (БЕЛДЕРҮНАМӘ) № ______

Шәһәр тибындагы Урыссу бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И. А.и.
____________________________________________________________________________
Адресы: _______________________________________________________________
Гражданнар җыены карары нигезендә _________торак пунктында 2020 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Шәһәр тибындагы Урыссу советы утырышы нигезендә, Сезгә _______ елга кадәр гражданнар җыены чараларын тормышка ашыру өчен _____ сум күләмендәге бер тапкыр түләнелә торган акчаны түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:
Банк получателя
БИК

Получатель
Сч. №
ИНН КПП
КБК
ОКАТО
Назначение платежа **самообложение граждан за 2020 год.**

Җитәкче ____________________ ________________________________________
М. У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -**

Хәбәрнамә (Белдерүнамә) № _________________
Ташкичү авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча________________ сум күләмендә бер тапкыр түләнелә торган акчаны түләү турында
(*муниципаль берәмлек исеме*)

Түләүченең Ф.И. А.и. __________________________________________________________
Адресы: ____________________________________________________________________________
Кабул ителде «__» _______________ 20__ елда ____________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Әгәр дә хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылса, өзелмә төпсә (отрывной корешок) тутырыла һәм Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетында калдырыла.*